# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 24 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Азалак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл жирлеге Юлтимер авылы торак пунктында “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Юлтимер авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Юлтимер авылында (Сабантуй, юбилейлар, 9 Май, өлкәннәр көне, инвалидлар көне) массакүләм чаралар үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Юлтимер авылында кыш көне юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Юлтимер авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- бензин чапкычлары, ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ-82.1 тракторына , ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары өчен запас частьләр сатып алу;
- сулыкны төзекләндеру (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Юлтимер авылы Яңа, Яшьләр,Үзәк,Тау урамнары буенча урамы буенча юлларны ремонтлау ( махсус техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү);
- Юлтимер авылы зираты территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма кую өчен түләү;
- Юлтимер авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар жыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү):

3. Әлеге карарны Азалак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче: И.Г.Габдулгазизов